**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О проверке достоверности и полноты сведений, представленных гражданами, претендующими на замещение муниципальных должностей, должности главы местной администрации по контракту, и лицами, замещающими муниципальные должности, должность главы местной администрации по контракту

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2017 года

## Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

1. Предметом регулирования настоящего Закона является порядок осуществления проверки:

1) достоверности и полноты сведений, представленных гражданами, претендующими на замещение муниципальных должностей в Республике Татарстан (далее – муниципальные должности), о своих доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруг (супругов) и несовершеннолетних детей (далее – сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера);

2) достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных лицами, замещающими муниципальные должности;

3) достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение должности главы местной администрации по контракту (далее – должность главы местной администрации);

4) достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных лицами, замещающими должность главы местной администрации.

2. Действие настоящего Закона не распространяется на лиц, для которых нормативными правовыми актами Российской Федерации и (или) законами

Республики Татарстан установлен иной порядок осуществления проверки сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера.

Статья 2. **Правовая основа проверки достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение муниципальных должностей, должности главы местной администрации, и лицами, замещающими муниципальные должности, должность главы местной администрации**

Правовую основу проверки достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение муниципальных должностей, должности главы местной администрации, и лицами, замещающими муниципальные должности, должность главы местной администрации, составляют Конституция Российской Федерации, Федеральный закон от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции» (далее – Федеральный закон «О противодействии коррупции»), Федеральный закон от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам» (далее – Федеральный закон «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам»), иные нормативные правовые акты Российской Федерации, Конституция Республики Татарстан, настоящий Закон, иные законы Республики Татарстан.

Статья 3. **Решение о проведении проверки достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение муниципальных должностей, должности главы местной администрации, и лицами, замещающими муниципальные должности, должность главы местной администрации**

Проверка достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных гражданами, претендующими на замещение муниципальных должностей, должности главы местной администрации, и лицами, замещающими муниципальные должности, должность главы местной администрации (далее – проверка), осуществляется по решению Президента Республики Татарстан. Решение принимается отдельно в отношении каждого гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, или лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, и оформляется в письменном виде.

Статья 4. **Орган, уполномоченный на проведение проверки**

Проверка осуществляется органом Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений.

Статья 5. **Основания для принятия решения о проведении проверки**

1. Основанием для принятия решения о проведении проверки, за исключением случаев, установленных частью 2 настоящей статьи, является достаточная информация, представленная в письменном виде:

1) правоохранительными органами, иными государственными органами, органами местного самоуправления и их должностными лицами;

2) органом Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений;

3) работниками подразделений кадровых служб органов местного самоуправления по профилактике коррупционных и иных правонарушений либо должностными лицами указанных органов, ответственными за работу по профилактике коррупционных и иных правонарушений;

4) постоянно действующими руководящими органами политических партий, региональными или местными отделениями политических партий, а также зарегистрированными в соответствии с законом общественными объединениями, не являющимися политическими партиями;

5) Общественной палатой Российской Федерации, Общественной палатой Республики Татарстан, общественным советом, созданным в соответствующем муниципальном образовании;

6) средствами массовой информации.

2. Основанием для принятия решения об осуществлении контроля за расходами лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, а также за расходами его супруги (супруга) и несовершеннолетних детей является достаточная информация о том, что данным лицом, его супругой (супругом) и (или) несовершеннолетними детьми в течение отчетного периода совершены сделки (совершена сделка) по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг, акций (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций) на общую сумму, превышающую общий доход данного лица и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих отчетному периоду. Указанная информация в письменном виде может быть представлена органами, организациями и (или) должностными лицами, указанными в части 1 статьи 4 Федерального закона «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам».

3. Информация анонимного характера не может служить основанием для проверки.

Статья 6. **Срок проведения проверки**

Проверка осуществляется в срок, не превышающий 60 дней со дня принятия решения о ее проведении. Указанный срок может быть продлен до 90 дней Президентом Республики Татарстан.

Статья 7. **Форма проведения проверки**

1. Орган Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений осуществляет проверку:

1) самостоятельно;

2) путем внесения в порядке, установленном настоящим Законом, предложений о направлении запроса в федеральные органы исполнительной власти, уполномоченные на осуществление оперативно-разыскной деятельности, в кредитные организации, налоговые органы и органы, осуществляющие государственную регистрацию прав на недвижимое имущество.

2. При осуществлении проверки должностные лица органа Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений вправе:

1) проверять соблюдение лицами, замещающими муниципальные должности, должность главы местной администрации, ограничений и запретов, требований о предотвращении или урегулировании конфликта интересов, исполнение ими должностных обязанностей, установленных Федеральным законом «О противодействии коррупции», другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами (далее – установленные ограничения);

2) изучать и анализировать сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленные гражданином, претендующим на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, лицом, замещающим муниципальную должность, должность главы местной администрации, и дополнительные материалы, которые приобщаются к материалам проверки;

3) получать пояснения: от гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, по представленным им сведениям о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера; от лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, по вопросу соблюдения им установленных ограничений, а также по материалам проверки;

4) направлять в установленном порядке запросы (кроме запросов в кредитные организации, налоговые органы и органы, осуществляющие государственную регистрацию прав на недвижимое имущество, а также запросов, касающихся оперативно-разыскной деятельности или ее результатов) в органы прокуратуры Российской Федерации, следственные органы Следственного комитета Российской Федерации, иные федеральные государственные органы, государственные органы Республики Татарстан, государственные органы иных субъектов Российской Федерации, территориальные органы федеральных органов государственной власти,

муниципальные органы, организации и общественные объединения об имеющихся у них сведениях: о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, а также их супруг (супругов) и несовершеннолетних детей; о соблюдении лицом, замещающим муниципальную должность, должность главы местной администрации, установленных ограничений;

5) наводить справки у физических лиц и получать от них информацию с их согласия.

3. При осуществлении контроля за расходами лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, а также за расходами его супруги (супруга) и несовершеннолетних детей орган Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений пользуется правами, исполняет обязанности, указанные Федеральным законом «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам».

Статья 8. **Содержание и порядок направления запросов**

1. В запросе, предусмотренном пунктом 4 части 2 статьи 7 настоящего Закона, указываются:

1) фамилия, имя, отчество руководителя государственного органа или организации, в которые направляется запрос;

2) сведения о нормативном правовом акте, на основании которого направляется запрос, и решении о проведении проверки;

3) фамилия, имя, отчество, дата и место рождения, место регистрации, жительства и (или) пребывания, должность и место работы (службы), вид и реквизиты документа, удостоверяющего личность, гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, а также их супруг (супругов) и несовершеннолетних детей, сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера которых проверяются; лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, в отношении которого имеются сведения о несоблюдении им установленных ограничений;

4) содержание и объем сведений, подлежащих проверке;

5) срок представления запрашиваемых сведений;

6) фамилия, инициалы и номер телефона должностного лица, подготовившего запрос;

7) идентификационный номер налогоплательщика;

8) другие необходимые сведения.

2. В случае, если при проведении проверки возникает необходимость проведения оперативно-разыскных мероприятий, направления запросов в кредитные организации, налоговые органы и органы, осуществляющие государственную

регистрацию прав на недвижимое имущество, руководитель органа Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений вносит предложение Президенту Республики Татарстан о направлении соответствующего запроса.

3. Запросы, касающиеся оперативно-разыскной деятельности или ее результатов, направляются Президентом Республики Татарстан. Запросы в кредитные организации, налоговые органы и органы, осуществляющие государственную регистрацию прав на недвижимое имущество, направляются Президентом Республики Татарстан либо в случаях, предусмотренных законодательством, уполномоченным им должностным лицом.

Статья 9. **Порядок исполнения запросов**

Руководители государственных органов, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений, в адрес которых поступил запрос, организовывают исполнение запроса и представляют запрашиваемую информацию в соответствии с федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации.

Статья 10. **Порядок проведения проверки**

1. Гражданин, претендующий на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, и лицо, замещающее муниципальную должность, должность главы местной администрации, вправе:

1) давать пояснения в письменном виде: в ходе проверки; по вопросам, указанным в пункте 2 части 2 настоящей статьи; по результатам проверки;

2) представлять дополнительные материалы и давать по ним пояснения в письменном виде;

3) обращаться в орган Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений с подлежащим удовлетворению ходатайством о проведении с ним беседы по вопросам, указанным в пункте 2 части 2 настоящей статьи;

4) пользоваться иными правами, установленными законодательством.

2. В ходе проверки орган Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений:

1) уведомляет в письменном виде гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, или лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, о начале в отношении него проверки в течение двух рабочих дней со дня получения соответствующего решения;

2) проводит в случае обращения гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, или лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, беседу с ним, в ходе которой он должен быть проинформирован о том, какие сведения и соблюдение каких установленных ограничений и требований

к служебному поведению подлежат проверке, в течение семи рабочих дней со дня получения обращения указанного гражданина или лица, а при наличии уважительной причины – в срок, согласованный с ним.

3. По окончании проверки орган Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений обязан ознакомить гражданина, претендующего на замещение муниципальной должности, должности главы местной администрации, или лицо, замещающее муниципальную должность, должность главы местной администрации, с результатами проверки с соблюдением законодательства Российской Федерации о государственной тайне.

4. Пояснения, указанные в части 1 настоящей статьи, приобщаются к материалам проверки.

5. В случаях, предусмотренных законодательством, на период проведения проверки лицо, замещающее муниципальную должность, должность главы местной администрации, может быть отстранено от замещаемой должности на срок, не превышающий 60 дней со дня принятия решения о ее проведении. Указанный срок может быть продлен до 90 дней по решению Президента Республики Татарстан. На период отстранения лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, от замещаемой должности денежное содержание по замещаемой им должности сохраняется.

6. По результатам проверки орган Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений направляет Президенту Республики Татарстан, а также по согласованию с ним должностному лицу (органу местного самоуправления), уполномоченному назначать (избирать, утверждать), представлять к назначению (избранию, утверждению) гражданина на муниципальную должность, должность главы местной администрации или назначившему (избравшему, утвердившему) лицо, замещающее муниципальную должность, должность главы местной администрации, на соответствующую муниципальную должность, должность главы местной администрации, доклад, в котором должно содержаться одно из следующих предложений:

1) о назначении (избрании, утверждении), представлении к назначению (избранию, утверждению) гражданина на муниципальную должность, должность главы местной администрации;

2) об отказе гражданину в назначении (избрании, утверждении), представлении к назначению (избранию, утверждению) на муниципальную должность, должность главы местной администрации;

3) об отсутствии оснований для применения к лицу, замещающему муниципальную должность, должность главы местной администрации, мер юридической ответственности;

4) о применении к лицу, замещающему муниципальную должность, должность главы местной администрации, мер юридической ответственности в соответствии с федеральным законодательством и настоящим Законом;

5) о представлении материалов проверки в комиссию по координации работы по противодействию коррупции в Республике Татарстан.

7. При выявлении в результате проверки достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера,

представленных в соответствии с законодательством Российской Федерации о противодействии коррупции депутатом, членом выборного органа местного самоуправления, выборным должностным лицом местного самоуправления, фактов несоблюдения ограничений, запретов, неисполнения обязанностей, которые установлены Федеральным законом «О противодействии коррупции», Федеральным законом «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами» (далее – Федеральный закон «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами»), Президент Республики Татарстан обращается с заявлением о досрочном прекращении полномочий депутата, члена выборного органа местного самоуправления, выборного должностного лица местного самоуправления в орган местного самоуправления, уполномоченный принимать соответствующее решение, или в суд.

8. При выявлении в результате проверки достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленных лицом, замещающим муниципальную должность, не указанную в части 7 настоящей статьи, а также должность главы местной администрации, фактов несоблюдения им ограничений, запретов, неисполнения обязанностей, которые установлены Федеральным законом «О противодействии коррупции», Федеральным законом «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами», Президент Республики Татарстан обращается с заявлением о досрочном прекращении полномочий лица, замещающего муниципальную должность, должность главы местной администрации, или применении в отношении его иного дисциплинарного взыскания в орган местного самоуправления, уполномоченный принимать соответствующее решение, или в суд.

9. При установлении в ходе проверки обстоятельств, свидетельствующих о наличии признаков преступления или административного правонарушения, материалы об этом представляются в государственные органы в соответствии с их компетенцией.

10. Сведения о результатах проверки по письменному согласованию с Президентом Республики Татарстан предоставляются органом Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений с одновременным уведомлением об этом гражданина или лица, в отношении которого проводилась проверка, правоохранительным органам, иным государственным

органам, органам местного самоуправления и их должностным лицам, постоянно действующим руководящим органам политических партий, региональным или местным отделениям политических партий, а также зарегистрированным в соответствии с законом общественным объединениям, не являющимся политическими партиями, Общественной палате Российской Федерации, Общественной палате Республики Татарстан, общественному совету, созданному в соответствующем муниципальном образовании, предоставившим информацию, явившуюся основанием для проведения проверки, с соблюдением законодательства Российской Федерации о персональных данных и государственной тайне.

11. Материалы проверки хранятся в органе Республики Татарстан по профилактике коррупционных и иных правонарушений в течение трех лет со дня ее окончания, после чего передаются в архив.

Статья 11. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань,Кремль
19 июля 2017 года
№ 57-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Законның җайга салу предметы түбәндәгеләрне тикшерү тәртибеннән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны (алга таба – муниципаль вазыйфалар) биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырылган үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең, шулай ук хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең (алга таба – керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр) дөреслеген һәм тулылыгын;

2) муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр дөреслеген һәм тулылыгын;

3) контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын (алга таба – җирле администрация башлыгы вазыйфасы) биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

4) җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары белән керемнәр, чыгымнар,

мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне тикшерүне гамәлгә ашыруның башка тәртибе билгеләнгән затларга кагылмый.

2 статья. **Муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүнең хокукый нигезе**

Муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүнең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль закон), “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” Федераль закон), Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары тәшкил итә.

3 статья. **Муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне үткәрү турында карар**

Муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү (алга таба – тикшерү) Татарстан Республикасы Президенты карары белән гамәлгә ашырыла. Карар муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы һәр гражданга яисә муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче һәр затка карата аерым кабул ителә һәм язма рәвештә рәсмиләштерелә.

4 статья. **Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтле орган**

Тикшерү Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Тикшерүне үткәрү турында карар кабул итү өчен нигезләр**

1. Тикшерүне үткәрү турында карар кабул итү өчен, әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, түбәндәгеләр тарафыннан язма рәвештә бирелгән җитәрлек мәгълүмат нигез булып тора:

1) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

2) Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы;

3) җирле үзидарә органнары кадрлар хезмәтләренең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлекчәләре хезмәткәрләре йә күрсәтелгән органнарның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары;

4) сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнары, сәяси партияләрнең төбәк яисә җирле бүлекләре, шулай ук закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган иҗтимагый берләшмәләр;

5) Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, тиешле муниципаль берәмлектә төзелгән иҗтимагый совет;

6) массакүләм мәгълүмат чаралары.

2. Муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат чыгымнарын, шулай ук аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен әлеге зат, аның хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган балалары тарафыннан хисап чоры дәвамында җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемннән арткан гомуми суммага алыш-бирешләр (алыш-биреш) башкарылу турында җитәрлек мәгълүмат нигез булып тора. Күрсәтелгән мәгълүмат язма рәвештә “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән органнар, оешмалар һәм (яисә) вазыйфаи затлар тарафыннан бирелергә мөмкин.

3. Аноним характердагы мәгълүмат тикшерү өчен нигез була алмый.

6 статья. **Тикшерүне үткәрү срогы**

Тикшерү аны уздыру турында карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән дә артыграк булмаган срокта үткәрелә. Күрсәтелгән срок Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

7 статья. **Тикшерүне үткәрү рәвешләре**

1. Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы тикшерүне түбәндәгечә үткәрә:

1) мөстәкыйль;

2) оператив эшчәнлек һәм эзләү эшчәнлеген башкаруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарына, кредит оешмаларына, салым органнарына һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органнарга гарызнамә җибәрү турында әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертү юлы белән.

2. Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органының вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль вазыйфалар, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләрнең үтәлешен, аларның "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законда, башка федераль законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән вазыйфаи бурычларны (алга таба – билгеләнгән чикләүләр) үтәүләрен тикшерергә;

2) муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне һәм тикшерү материалларына өстәлә торган өстәмә материалларны өйрәнергә һәм анализларга;

3) муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнан, муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче заттан ул тапшырган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр буенча; муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче заттан аның билгеләнгән чикләүләрне үтәве мәсьәләсе, шулай ук тикшерү материаллары буенча аңлатмалар алырга;

4) муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданның, муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында; муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның билгеләнгән чикләүләрне үтәве турында үзләрендә булган белешмәләрне сорап Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының тикшерү органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт органнарына, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарына, муниципаль органнарга, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр (кредит оешмаларына, салым органнарына һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы

органнарга гарызнамәләрдән, шулай ук оператив эшчәнлеккә һәм эзләү эшчәнлегенә яисә аның нәтиҗәләренә кагылышлы гарызнамәләрдән тыш) җибәрергә;

5) физик затлардан, аларның ризалыгы белән, белешмәләр җыярга һәм мәгълүмат алырга.

3. Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат чыгымнарын, шулай ук аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашырганда "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль законда күрсәтелгән хокуклардан файдалана, бурычларны башкара.

8 статья. **Гарызнамәләрнең эчтәлеге һәм аларны җибәрү тәртибе**

1. Әлеге Законның 7 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында каралган гарызнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гарызнамә җибәрелә торган дәүләт органы яисә оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) гарызнамә җибәрү нигезләнә торган норматив хокукый акт һәм тикшерүне үткәрү турындагы карар хакында белешмәләр;

3) керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләре тикшерелә торган муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданның, муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының; билгеләнгән чикләүләрне үтәмәве турында белешмәләр булган муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, теркәлү, яшәү һәм (яисә) булу урыны, вазыйфасы һәм эш (хезмәт) урыны, шәхесен таныклаучы документның төре һәм реквизитлары;

4) тикшерелергә тиешле белешмәләрнең эчтәлеге һәм күләме;

5) соратылган белешмәләрне тапшыру срогы;

6) гарызнамә әзерләгән вазыйфаи затның фамилиясе, инициаллары һәм телефон номеры;

7) салым түләүченең идентификация номеры;

8) кирәкле башка белешмәләр.

2. Тикшерүне үткәргәндә оператив чаралар һәм эзләү чаралары үткәрү, кредит оешмаларына, салым органнарына һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органнарга гарызнамәләр җибәрү зарурлыгы барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы җитәкчесе тиешле гарызнамә җибәрү турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим кертә.

3. Оператив эшчәнлеккә һәм эзләү эшчәнлегенә яисә аның нәтиҗәләренә кагылышлы гарызнамәләр Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан

җибәрелә. Кредит оешмаларына, салым органнарына һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органнарга гарызнамәләр Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан йә, законнарда каралган очракларда, ул вәкаләт биргән вазыйфаи зат тарафыннан җибәрелә.

9 статья. **Гарызнамәләрне үтәү тәртибе**

Гарызнамә килгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гарызнамәне үтәүне оештыра һәм сорала торган мәгълүматны бирә.

10 статья. **Тикшерүне үткәрү тәртибе**

1. Муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан һәм муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү барышында; әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча; тикшерү нәтиҗәләре буенча язмача аңлатмалар бирергә;

2) өстәмә материаллар тапшырырга һәм алар буенча язмача аңлатмалар бирергә;

3) Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органына әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча үзе белән әңгәмә үткәрү турында һичшиксез канәгатьләндерелергә тиешле үтенечнамә белән мөрәҗәгать итәргә;

4) законнарда билгеләнгән башка хокуклардан файдаланырга.

2. Тикшерүне үткәргәндә Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы түбәндәгеләрне башкара:

1) тиешле карарны алган көннән алып ике эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданга яисә муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка аңа карата тикшерү башлану турында язма рәвештә хәбәр итә;

2) муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан яисә муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән гражданның яисә затның мөрәҗәгате алынганнан соң җиде эш көне эчендә, ә нигезле сәбәп булганда аның белән килештерелгән вакытта шушы граждан яисә зат белән әңгәмә үткәрә, аның барышында аңа нинди белешмәләр һәм билгеләнгән нинди чикләүләрне, хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү тикшерелергә тиешлеге турында мәгълүмат бирелергә тиеш.

3. Тикшерү тәмамланганнан соң Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданны яисә

муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затны, Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнарын үтәп, тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга тиеш.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәп куела.

5. Законнарда каралган очракларда, муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тикшерү вакытына аны үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән дә артык булмаган вакытка биләгән вазыйфасыннан читләштерелергә мөмкин. Күрсәтелгән срок Татарстан Республикасы Президенты карары белән 90 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин. Муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затны биләгән вазыйфасыннан читләштерү чорына ул биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү саклана.

6. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы Татарстан Республикасы Президентына, шулай ук аның белән килештереп муниципаль вазыйфага, җирле администрация башлыгы вазыйфасына гражданны билгеләп куярга (сайлап куярга, расларга), билгеләп куюга (сайлап куюга, раслауга) тәкъдим итәргә вәкаләтле яисә муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затны тиешле муниципаль вазыйфага, җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләп куйган (сайлап куйган, раслаган) вазыйфаи затка, (җирле үзидарә органына) доклад җибәрә, анда түбәндәге тәкъдимнәрнең берсе булырга тиеш:

1) гражданны муниципаль вазыйфага, җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләп кую (сайлап кую, раслау), билгеләп куюга (сайлап куюга, раслауга) тәкъдим итү турында;

2) гражданны муниципаль вазыйфага, җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләп куюдан (сайлап куюдан, раслаудан), билгеләп куюга (сайлап куюга, раслауга) тәкъдим итүдән баш тарту хакында;

3) муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка карата юридик җаваплылык чараларын күрүгә нигезләр булмавы турында;

4) муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затка карата федераль законнар һәм әлеге Закон нигезендә юридик җаваплылык чараларын күрү хакында;

5) тикшерү материалларын Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенә тапшыру турында.

7. Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары нигезендә депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны

һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" Федераль закон) билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны башкармау фактлары ачыклангандa, Татарстан Республикасы Президенты депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.

8. Әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелмәгән муниципаль вазыйфаны, шулай ук җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә аның тарафыннан "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законда, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль законда, "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны башкармау фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты муниципаль вазыйфаны, җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә аңа карата башка дисциплинар җәза куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.

9. Тикшерү барышында җинаять яисә административ хокук бозу билгеләре булуны күрсәтә торган хәлләр ачыкланганда, бу хакта материаллар аларның компетенцияләренә карап дәүләт органнарына бирелә.

10. Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органы, Татарстан Республикасы Президенты белән язмача килештереп, персональ белешмәләр һәм дәүләт сере турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәп, бер үк вакытта аңа карата тикшерү үткәрелгән гражданга яисә затка хәбәр итеп, тикшерү нәтиҗәләре турында белешмәләрне тикшерүне үткәрүгә нигез булган мәгълүмат биргән эчке эшләр органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнарына, сәяси партияләрнең төбәк яисә җирле бүлекләренә, шулай ук закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган иҗтимагый берләшмәләргә, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, тиешле муниципаль берәмлектә төзелгән иҗтимагый советка бирә.

11. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау органында ул тәмамланган көннән алып өч ел дәвамында саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 19 июль
№ 57-ТРЗ